**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**Сарман авыл жирлеге**
**423350 Сарман авылы, Ленин ур.,52**
**тел.: 2-43-67, 2-45-38**
**E - mail: sar.sar@tatar.ru**
ИНН/КПП 1636005461/163601001

**Сармановское сельское поселение**
**САРМАНОВСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
**423350 с. Сарманово, ул.Ленина, 52**
**тел.: 2-43-67, 2-45-38**
**E – mail: sar.sar@tatar.ru**
ИНН/КПП 1636005461/163601001

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
6 июня 2016 г. № 6

2016 елның су коену сезонында
су объектларында кешеләрнең
иминлеген тәэмин итү чаралары турында

Халыкның сәламәтлеген саклау һәм йогышлы авырулар санын кисәтү максатларында, «халыкның санитар-эпидемиология иминлеге турында» 1999 ел,30 март, 52-ФЗ номерлы Федераль законның 18, 51 статьялары нигезендә, «Сарман авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, "халык сәламәтлеген саклау һәм йогышлы авырулар санын кисәтү" максатыннан чыгып, "Сарман авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставына таянып,

карар бирәм:

1. «Сарман авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең су объектының санитар кагыйдәләргә һәм халыкның сәламәтлеге өчен куркынычсыз булган су объектыннан файдалану шартларына туры килүе турында санитар-эпидемиологик бәяләмә булмаган ачык сулыкларда халыкны су коендыруны тыю. Башкар комитка су керергщ тыела торган сулыкларга «Су коену тыела!» тыю билгелщре куярга.

2. Су коену сезоны вакытында, сулыклар янындагы хәлне контрольдә тоту максатыннан, ДНД арасыннан җәяүлеләр патрульләре, коткару постлары булдырырга. Сулыкларда халык күпләп ял итә торган урыннарда куркынычсызлыкны контрольдә тоту максатыннан РФ Эчке эшләр министрлыгы хезмәткәрләре белән уртак рейдлар оештырырга.

3. Башкарма комитет массакүләм мәгълүмат чаралары белән берлектә ачык сулыкларда коену куркынычы турында халык белән аңлату эшләре алып барырга тиеш.

4. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында», PRAVO.TATARSTAN.RU( Татарстан Республикасы «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

5. «Сарман ЦРБ» белән берлектә судагы бәхетсезлек очракларында беренче медицина ярдәме күрсәтү буенча халык арасында аңлату эшен оештырырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Сарман муниципаль районы
Сарман авыл җирлеге
Башкарма Комитет җитәкчесе И.Я.Хасанов